| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |
|---|---|

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

24 июнь 2020 ел №3-58

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Буа шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә
салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, "Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында" 2014 елның 31 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Буа шәһәр Советы карар кылды:

I. Буа муниципаль районы Буа шәһәр Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 1-39 номерлы (2015 елның 21 маендагы 3-45 номерлы, 2015 елның 9 октябрендәге 6-2 номерлы, 14.11.2018 елдагы 3-37 номерлы карарлары редакциясендә) «Физик затлар милкенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертергә:

5 пунктның 4 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым ташламасына хокуклы зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукны раслаучы документлар тапшыра. Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан елның 1 ноябренә кадәр салым чоры булып торучы, әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым органына тапшырыла. Сайлап алынган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин.».

II. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

III. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча бастырылып чыгарылырга тиеш..

Буа муниципаль районының
Буа шәһәре башлыгы урынбасары С.А. Зайцева